ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2025 ел Баулы шәһәре № 143

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының "Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Баулы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында" 2011 елның 22 июнендәге 134 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 6 сентябрендәге 669 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Баулы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 22 июнендәге 134 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 10.12.2012 №281, 24.10.2013 №252, 22.01.2014 №18, 31.10.2014 №330, 20.11.2015 №319, 08.07.2016 №219, 10.08.2017 №350, 15.01.2018 №11, 06.12.2021 №213, 30.12.2022 №282, 04.06.2024 №81, 07.11.2024 №153, 24.04.2025 №50 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

күрсәтелгән карарга 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

карарына 1 нче кушымта
(Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025елның 14 декабрендәге
143 номерлы карары редакциясендә)

Баулы муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренә түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сумнар |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 25 650 |
| 2 | 1,0113 | 25 940 |
| 3 | 1,0234 | 26 250 |
| 4 | 1,0347 | 26 540 |
| 5 | 1,0476 | 26 871 |
| 6 | 1,0596 | 27 180 |
| 7 | 1,0729 | 27 520 |
| 8 | 1,0858 | 27 851 |
| 9 | 1,0982 | 28 170 |
| 10 | 1,1119 | 28 520 |
| 11 | 1,1251 | 28 860 |
| 12 | 1,1392 | 29 220 |
| 13 | 1,1536 | 29 590 |
| 14 | 1,1676 | 29 950 |
| 15 | 1,1825 | 30 331 |
| 16 | 1,1973 | 30 711 |
| 17 | 1,2125 | 31 100 |
| 18 | 1,2281 | 31 501 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 - 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.